**ГЛАВА**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

04.10.2019 Исәнбай авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Исәнбай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1. Исәнбай мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 елның 17 октябренә 11 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:
« Исәнбай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан, иректән мәхрүм ителгән физик затлардан тыш, 2020 елда узара салым акчасын 350 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1) Исәнбай авыл җирлеге территориясендәге сууткәргеч челтәре өчен су насослары, колонкалар, ремонт очен сантехник материаллар, сууткәргечләрне алмаштыру өчен полиэтилин торбалар һәм краннар сатып алу;
2) Исәнбай авыл җирлеге территориясендәге урам утларының төзеклеге очен материаллар, алмаштыру өчен лампалар, дроссельләр һәм фонарьлар сатып алу;
3) Авыл территориясенә кергән юлларны кардан чистарту;

4) Исәнбай авыл җирлеге өчен МТЗ-82 тракторы сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК".

3. Исәнбай авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ф.Ф.СИРАЕВ